**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«19» 10 2023 ел Яр Чаллы № 3493

«2021-2023 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» программасын раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 22 гыйнварендәге 128 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 16 маендагы 1064-р номерлы күрсәтмәсе һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә физик культура, массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тәэмин итүгә, рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыруга бәйле чараларны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2021-2023 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» программасын раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 22 гыйнварендәге 128 номерлы карарына 2023 елга Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесен финанслау күләмен Татарстан Республикасы «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты хисабына 2716,00 сум күләмендә арттыру турында үзгәрешләр кертергә.
2. «2021-2023 елларга Тукай муниципаль районында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, физик культура һәм спортны үстерү» программасы паспортының «Программаны еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп финанслау күләмнәре» бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Программаны еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп финанслау күләмнәре | 2021-2023 елларда ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 13855584,70 сум тәшкил итә, шул исәптән: |

| | |
|---|---|
| | 2021 елда – 7 267 568,70 сум;<br>2022 елда – 2 099 600,00 сум;<br>2023 елда – 2 381 366,00 сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм тиешле елга һәм план чорына бюджет проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш.<br>Республика, федераль бюджет акчалары һәм бюджеттан тыш чыганаклар ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк. |

3. «2021-2023 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» программасының «Профилактик чаралар һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча чаралар» II бүлеге «Район территориясендә физик культураны, массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итүгә бәйле чаралар, рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру (Аутсорсинг)» пунктына 2716,00 сум күләмендә финанс средстволарын кушымта нигезендә өстәргә.

4. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә әлеге карарны 3 эш көне эчендә районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары И.Ш. Бариевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкар комитетының 2023 елның 19.10 3493 номерлы карарына кушымта

**«2021 - 2023 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» программасын гамәлгә ашыру буенча чаралар**

| № | Чаралар исеме | Финанс чараларын бүлү, еллар буенча (сумнарда) | | | | Финанслау чыганагы | Башкаручы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | Барлыгы | | |
| II. Профилактик чаралар һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча чаралар | | | | | | | |
| 1. | Район территориясендә физик культураны, массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыруга бәйле чаралар, рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру (Аутсорсинг) | 326070 | | 271600 | 597670 | Республика бюджеты | Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» ӨББ МБУ |
| 2. | | 3260,70 | | 2716,00 | 5976,70 | Район бюджеты | |